КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 ноябрь г.Казань № 1055

Татарстан Республикасының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төбәк әһәмиятендәге объектларны урнаштыру өчен «Фатыйх Әмирхан урамы, Чистай урамы, Гаврилов урамы һәм Казансу елгасы яры белән чикләнгән территория – Казансу елгасының уң яры» территориясен планлаштыру проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төбәк әһәмиятендәге объектларны урнаштыру өчен «Фатыйх Әмирхан урамы, Чистай урамы, Гаврилов урамы һәм Казансу елгасы яры белән чикләнгән территория – Казансу елгасының уң яры» территориясен планлаштыру проектын расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казансу елгасында спорт корылмалары комплексы» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру проектын раслау турында» 2009 ел, 30 декабрь, 906 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин